**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Об установлении карантина на территории села Бурнашево Чистопольского района Республики Татарстан и на отдельной территории города Казани в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных**

В связи с выявлением заболевания бешенством животных и угрозой его распространения в населенных пунктах Республики Татарстан, в соответствии со статьями $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю:**

1. Установить карантин в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территории села Бурнашево Чистопольского района Республики Татарстан;

б) на территории садоводческого некоммерческого товарищества «Подгорный» в городе Казани.

2. На территориях, указанных в пункте 1 настоящего Указа, в период действия карантина запрещаются:

торговля домашними животными, их вывоз за пределы соответствующей территории и отлов (для вывоза в зоопарки, с целью расселения в других районах) диких животных;

убой на мясо животных, больных или подозрительных по заболеванию бешенством;

реализация, использование в пищу и для скармливания животным молока от животных, больных бешенством;

реализация, использование в пищу и для скармливания животным молока от клинически здоровых животных без пастеризации в установленном порядке;

вывоз за пределы соответствующей территории шерсти, шкур, полученных от клинически здоровых животных и не прошедших дезинфекцию в установленном порядке.

3. Установить, что карантин подлежит отмене по истечении двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством при условии выполнения необходимых мероприятий.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить планы мероприятий по ликвидации бешенства животных на территориях, указанных в пункте 1 настоящего Указа, а также обеспечить их реализацию.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
17 декабря 2019 года
№ УП-758

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Чистай районының Борнаш авылы территориясендә һәм Казан шәһәренең аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасы Чистай районының Борнаш авылы территориясендә;

б) Казан шәһәрендәге «Подгорный» коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте территориясендә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләр (аларны зоопаркларга чыгару, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны иткә сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы кененнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БУЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 17 декабрь
№ ПУ-758